| | |
|---|---|
| **МИНИСТЕРСТВО ФИНАНСОВ РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ФИНАНС МИНИСТРЛЫГЫ** |

**ПРИКАЗ** **БОЕРЫК**

01.02.2017 № 21-95-18

Казан ш.

Татарстан Республикасы Финанс министрлыгының 08.09.2015 ел, № 21-95-58 боерыгы белән расланган Баш администраторлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары булып торган керемнәр төрләре буенча кече төрләрнең кодлары исемлегенә үзгәрешләр кертү турында

“Россия Федерациясе Финанс министрлыгының 1 июль, 2013 ел, № 65н боерыгы белән расланган Россия Федерациясе бюджет классификациясен куллану тәртибе турында күрсәтмәләргә үзгәрешләр кертү хакында” 7 декабрь 2016 ел, № 230н Россия Федерациясе Финанс министрлыгы боерыгы чыгарылуга бәйле рәвештә, боерык бирәм:

1.“Баш администраторлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары булып торган керемнәр төрләре буенча кече төрләрнең кодлары исемлеген раслау турында” 08.09.2015 ел, № 21-95-58 Татарстан Республикасы Финанс

министрлыгы боерыгы белән расланган Баш администраторлары Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте органнары булып торган керемнәр төрләре буенча кече төрләрнең кодлары исемлегенә (Татарстан Республиткасы Финанс министрлыгының 27.04.2016 ел, № 21-95-24 боерыгы белән расланган үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешне кертергә:

юлдан соң:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «000 1 08 07400 01 0000 110 | Россия Федерациясе субъектлары вәкаләтле органнарының күп фатирлы йортлар белән идарә итү буенча эшмәкәрлек эшчәнлеген лицензияләүгә бәйле гамәлләре өчен дәүләт пошлинасы | 1000 | түләү суммасы (тиешле түләү буенча, шул исәптән бетерелгән түләү буенча яңадан исәп-хисап ясаулар, недоимка һәм бурыч)” |

түбәндәге эчтәлектәге юлны өстәргә:

| | | | |
|---|---|---|---|
| «000 1 08 07420 01 0000 110 | Кунакханәләрне һәм кешеләрне урнаштыруның башка чараларын, тау чаңгысы трассаларын, комлыкларны кертеп, | 1000 | түләү суммасы (тиешле түләү буенча, шул исәптән бетерелгән түләү буенча яңадан исәп- |

| | | | |
|---|---|---|---|
| | туристлык индустриясе объектларын классификацияләүне хәл итүче оешмаларны аккредитацияләү турында документлар бирүгә дәүләт пошлинасы | | хисап ясаулар, недоимка һәм бурыч)” |

2. Бу боерыкның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплылыгымда калдырам.

Министр Р.Р.Гайзатуллин